**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» **июнь 2026ел** *Мөслим* **№ 219**

**2026-2027 уку елына мәктәп автобус маршрутларын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы - ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 3 августындагы, 400 номерлы карарлары нигезендә (ТР Министрлар Кабинетының 2007елның 29 ноябрендәге 669 номерлы, 2016 елның 30 декабрендәге 1070 номерлы, 2018 елның 23 гыйнварындагы 29 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы 192 номерлы карарлары, керткән үзгәрешләр белән), РФ мәгариф министрлыгының 2022 елның 2 сентябрендәге методик тәкъдимнәре белән «Гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру» һәм «Мәктәп автобус маршрутын ачу турында Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 3 августындагы 615 номерлы методик тәкъдимнәр белән, укучыларны база гомуми белем бирү мәктәпләренә һәм кирегә балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобуслар белән даими йөртүне оештыру максатларында,ТР Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2026-2027 уку елына мәктәп автобус маршрутларын расларга:

**1 нче Маршрут** «Мөслим ав. (гимназия) - Мәлләтамак ав. - Катмыш ав. – Мөслим авылы»;

**2 нче Маршрут** «Мөслим ав. (гимназия) – Тамьян ав. Түбән Табын ав. — Тугаш авылы-Югары Табын ав. - Мөслим ав.»;

**3 нче Маршрут** «Мөслим ав. (гимназия) – Нарат - асты ав. – Мөслим ав.»;

**4 нче Маршрут** « Мөслим ав.– гимназия) - Бикмәч авылы– Яңа Усы ав.»– Салауз - Мухан-Мөслим авылы»;

**5 нче Маршрут** « Мөслим ав. (МСОШ)–Ольгино ав. – Метрәй ав.– Мөслим авылы»;

**6 нчы Маршрут** «Мөслим авылы – МСОШ) - Симәк авылы-Елгабаш авылы-Краснояр - Мөслим ав.»;

**7 нче Маршрут** «Мөслим авылы (МСОШ)– Иске Вәрәш авылы– Мөслим авылы»;

**8 нче Маршрут** «Мөслим авылы (лицей) – Вәрәшбаш авылы – Мөслим авылы»;

**9 нчы Маршрут** «Мөслим авылы (лицей) –Чия түбә җирлеге - Баланны авылы-Шуганка авылы-Мөслим авылы»;

**10 нчы маршрут** «Мөслим авылы (лицей)– Тойгелде авылы-Мөслим авылы»

**11 нче Маршрут** «Михайловка авылы (УГББМ)– Рантамак авылы (Сарман) муниципаль районы)– Элемтә авылы - Михайловка авылы»;

**12 нче Маршрут** «Михайловка авылы (УГББМ) – Атлас авылы– Ташлыяр авылы – Михайловка авылы»;

**13 нче Маршрут** «Күбәк ав. (УГББМ)– Баек ав. - Дусай ав. - Яңа Карамалы ав.– Түреш ав. - Кубәк ав.»;

**14 нче Маршрут** «Күбәк ав. (УГББМ)– Сөякәй ав.– Октябрь ав.– Күбәк ав.»;

**15 нче Маршрут** «Әмәкәй ав. (УГББМ) – Сөякәй ав. - Иске Әлмәт ав.– Әмәкәй авылы»;

**16 нчы Маршрут** «Баек ав. (ТГББМ)– Яңа Сәфәр җирлеге-Дусай ав.-

Баек авылы»;

**17 нче Маршрут** «Тат Бүләр авылы (УГББМ) - Сикия авылы - Иске Сәет авылы – Үрәзмәт авылы-Тат Бүләр авылы»;

**18 нче Маршрут** «Тат Бүләр авылы (УГББМ) - Исәнсеф авылы-Яңа Сәет авылы-Татар Бүләр авылы»;

**19 нчы Маршрут** « Мари-Бүләр ав. (ТГББМ) - Чишмә ав. - Яңа Сәет ав. – Осиновка җирлеге-Мари-Бүләр авылы»;

**20 нче Маршрут** «Югары Табын ав «(ТГББМ)–Тугаш авылы-Түбән Табын ав.– Тегермәнлек ав. - Югары Табын ав.»;

**21 нче Маршрут** «Салауз Мухан авылы (ТГББМ)- Мөслим авылы (гимназия, мсош) – Салауз Мухан ав»

**22 нче Маршрут** «Мөслим ав. (лицей)- Рус Шуганы ав. – Олы Чакмак ав. – Мөслим ав.»;

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 - 2025 уку елына мәктәп автобус маршрутларын раслау турында» 2024 елның 14 июнендәге 277 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 - 2025 уку елына мәктәп автобус маршрутларын раслау турында» 2024 елның 14 июнендәге 277номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 20 сентябрендәге 405 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына (Хәбибуллина Л.Я.) әлеге карарны Мөслим муниципаль районы территориясендә балаларны мәктәп автобусларында расланган маршрутлар буенча йөртүче гомуми белем бирү мәктәпләренә җиткерергә, аларның әлеге карарны һәм укучыларны йөртү эшчәнлеген җайга сала торган башка норматив актларны үтәвен тәэмин итәргә.

4. «Төзекләндерү һәм яшелләндерү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорына (Шәймөхәммәтов М. Д.) түбәндәгеләрне йөкләргә:

- нигезләмәләр нигезендә һәр мәктәп автобус маршрутына паспорт эшләү, килештерү һәм раслау;
- укучыларны имин йөртүне оештыру өчен норматив-хокукый актлар исемлеге нигезендә документлар пакетын әзерләү;
- транспорт чарасының хәрәкәт графигын һәм укучыларны утырту-төшерү урыннарының урнашу графигын раслау;
- автобусларны катгый рәвештә расланган маршрутлар һәм расписаниеләр нигезендә эксплуатацияләүне тәэмин итү;
- тиешле өзлексез машина йөртү стажы булган «Д» категорияле йөртүчеләр составын сайлап алуны тәэмин итү һәм тиешле инструктажлар үткәрү;
- автобусларны техник яктан төзек хәлдә тоту.

5. «Татавтодор» ААҖнең Минзәлә филиалы Мөслим участогы башлыгына (Гәрәев И.Р.) Мәктәп автобус маршрутларында автомобиль юлларының эксплуатация торышын яхшыртуга һәм техник төзекләндерүне камилләштерүгә өстәмә чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

6. Мөслим муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына укучыларны йөртү оештырылган юлларны һәм урамнарны куркынычсызлык таләпләренә туры китерергә, торак пунктларда мәктәп маршрутларының борылыш урыннарын һәм тукталыш пунктларын җиһазларга, балаларны утырту (төшерү) өчен мәктәп автобусы тукталган урыннарга юл билгеләре һәм күрсәткечләр куярга.

7. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Мөслим муниципаль районы буенча бүлеге ОГАИ начальнигына (Магданов Ф.М.) мәктәп автобус маршрутларында юлларның торышын һәм хәрәкәт иминлеген даими контрольдә тотуны тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Финанс - бюджет

палатасы рәисенә (Бубекова Н.А.) чираттагы финанс елына бюджет төзегәндә мәктәп автобусларын тоту чыгымнарын карарга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль - мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф. Салихҗанов**